ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31 октябрь 2023ел № 10495

«2024-2026 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә «Куркынычсыз шәһәр» АПК сегментын төзү һәм үстерү» муниципаль программасын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 3 декабрендәге 2446-р номерлы боерыгы белән расланган «Куркынычсыз шәһәр» аппарат-программа комплексын төзү һәм үстерү концепциясен үтәү йөзеннән, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2024-2026 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә «Куркынычсыз шәһәр» АПК сегментын төзү һәм үстерү» муниципаль программасын (алга таба – Программа) кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә Программаны үтәү буенча чаралар үтәлешен оештыруны тәэмин итәргә.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2024-2026 елларга Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә «Куркынычсыз шәһәр» АПК сегментын төзү һәм үстерү» муниципаль программасы чараларын финанслауны шәһәр бюджеты акчалары хисабына – 29 730,00 мең сум: 2024 ел – 9 910,00 мең сум, 2025 ел – 9 910,00 мең сум, 2026 ел – 9 910,00 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 31 октябрендәге
10495 номерлы карарына
кушымта

«2024-2026 елларга Яр Чаллы шәһәре»
муниципаль берәмлеге территориясендә
«Куркынычсыз шәһәр» АПК сегментын төзү һәм үстерү»
муниципаль программасы

Муниципаль программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2024-2026 елларга Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә «Куркынычсыз шәһәр» АПК сегментын төзү һәм үстерү» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | 1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>2. РФ Хөкүмәтенең «Куркынычсыз шәһәр» аппарат-программа комплексын төзү һәм үстерү концепциясен раслау турында» 2014 елның 3 декабрендәге 2446-р номерлы боерыгы;<br>3. ТР Министрлар Кабинетының «Кешеләр күпләп була торган объектларны видеокүзәтү камералары белән җиһазландыруга тәкъдимнәрне раслау турында» 2015 елның 26 октябрендәге 2399-р номерлы боерыгы;<br>4. ТР Министрлар Кабинетының «Куркынычсыз шәһәр» аппарат-программа комплексын тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасында видео мониторингы системасын үстерү концепциясен раслау турында» 2017 елның 21 гыйнварындагы 87-р номерлы боерыгы;<br>5. Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары. |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе |
| Программаны башкаручылар | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе |
| Программаның максаты | Җәмәгать иминлегенең, хокук тәртибенең һәм яшәү тирәлеге куркынычсызлыгының гомуми дәрәҗәсен арттыру |
| Программаның бурычлары | Яр Чаллы шәһәре территориясендә иҗтимагый киңлекләрендә һәм күпфатирлы йортлар территориясендә тәртип һәм куркынычсызлыкның даими мониторингын тәэмин итү |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2024-2026 еллар |

<table>
<tr><td rowspan="5">Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганагы</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2024 ел, мең сум</td><td>2025 ел, мең сум</td><td>2026 ел, мең сум</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы мең сум</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>9 910,00</td><td>9 910,00</td><td>9 910,00</td><td>29 730,00</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>9 910,00</td><td>9 910,00</td><td>9 910,00</td><td>29 730,00</td></tr>
<tr><td colspan="5">Искәрмә. Программаны тормышка ашыруга тотыла торган акчаларның күләме шәһәр бюджеты мөмкинлекләреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге инфляция процессларыннан һәм икътисадый хәлдән чыгып анykланырга һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="5">Яр Чаллы шәһәре территориясендә җәмәгать иминлеген һәм хокук тәртибен тәэмин итү</td></tr>
<tr><td>Программа үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы</td><td colspan="5">Программа үтәлешенә гомуми контрольне Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары гамәлгә ашыра</td></tr>
</table>

## 1 бүлек. Программаны тормышка ашыру өлкәсенең гомуми характеристикасы, төп проблемалар һәм аларны хәл итү юллары

Әлеге Программа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 3 декабрендәге 2446-р номерлы боерыгы белән расланган «Куркынычсыз шәһәр» аппарат-программа комплексын төзү һәм үстерү концепциясен үтәү йөзеннән эшләнде.

Заманча технологияләрдән файдалану шәһәрнең тотрыклы үсешенә ирешү өчен кирәкле шарт булып тора. Заманча технологияләрнең күптөрлелеге һәм креативлыгы ресурсларны экономияләү, гадел нигездә мәгълүматны тоткарлыксыз алмашу һәм шәһәрдә эшләүнең нәтиҗәлерәк ысулларын булдыру өчен машиналар һәм кешеләр арасындагы коммуникацияне җиңеләйтү өчен гаять зур потенциал турында сөйли.

Җирле үзидарә органнарының һәм гражданнарның үзара хезмәттәшлеге аеруча әһәмияткә ия. Бүген муниципаль бергәлекне, җирле хакимият органнарын, урыннардагы актив гражданнарны региондагы идарә, технологик, мәгълүмати процессларга кертү мөһим. Муниципаль идарәдә цифрлы технологияләр ресурсларны оператив һәм дөрес исәпкә алырга мөмкинлек бирәчәк, кабул ителә торган карарларның нәтиҗәлелеген һәм планлаштыру төгәллеген арттырачак.

Куркынычсызлык өлкәсендә яңа цифрлы технологияләрне гамәлгә кертү эшчәнлеген тәртипкә салу өчен, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе эшенең өстенлекле юнәлешләрен билгели торган Программа эшләнде. Программа шәһәр мохите сыйфатын күтәрүнең төп таләпләрен үтәүгә, Яр Чаллы шәһәре территориясендә яшәүчеләргә уңайлы һәм имин яшәү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

Заманча шәһәр мохитенең мөһим өлеше булып аның иминлеге тора. Шул сәбәпле, күпфатирлы йортларны, җәмәгать урыннарын һәм кешеләр күпләп җыела торган урыннарны видеокүзәтү системалары белән җиһазландыру эшен дәвам итәргә кирәк.

Социаль инфраструктура объектларының, атап әйткәндә, муниципаль мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте, спорт һәм физик культура учреждениеләре, шул исәптән аларның балалар бакчалары, мәктәпләр, өстәмә белем бирү объектлары, спорт объектлары, мәдәният объектлары, яшүсмерләр һәм яшьләр сәясәте объектлары, балаларны сәламәтләндерү лагерьлары, парклар һәм скверлар һәм башкалар кергән филиалларының һәм бүлекчәләренең куркынычсызлыгына аерым игътибар бирү таләп ителә.

## 2 бүлек. Тормышка ашыру срокларын күрсәтеп, Программаның максатлары һәм бурычлары, чаралар исемлеге һәм аларга кыскача тасвирлама

Яр Чаллы шәһәрендә видеокүзәтү системасын үстерү максаты булып, шәхеснең һәм җәмгыятьнең икътисадый, социаль, сәяси һәм рухи үсеше өчен гамәлдәге куркынычлар һәм хәвефләр минималь дәрәҗәдә киметелгән уңайлы шартлар тудыру тора, бу исә шәһәрне Татарстан Республикасында иң куркынычсыз шәһәрләрнең берсенә әверелдерергә мөмкинлек бирәчәк.

Видеокүзәтү системасын кертү бурычлары:

1. Шартлар мониторингы, кызыксынучы структураларга һәм ведомстволарга идарә карарларын кабул итү өчен мәгълүмат формалаштыру һәм бирү вакытын кыскарту;

2. Җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү, хокук бозуларны профилактикалау:

2.1. Гражданнарның тормыш иминлеген һәм сәламәтлеген, аларның мөлкәти мәнфәгатьләрен тәэмин итү;

2.2. Яшәешне тәэмин итү объектлары эшчәнлегенең куркынычсызлыгын тәэмин итү;

2.3. Террорчылык һәм экстремизм эшчәнлегенә каршы тору нәтиҗәлелеген арттыру;

2.4. Җәмгыятьтә криминаллаштыру дәрәҗәсенең кимүе;

2.5. җинаятьләр кылган затларны «кайнар эз» буенча билгеләү;

2.6. Мөһим объектлар, кешеләр күпләп җыела торган урыннар янында террорчылык акты һәм криминаль гамәлләр үткәрү ихтималын максималь киметү;

2.7. Барлык хезмәтләрнең җинаятьләрне ачудагы гамәлләрен килештерүне тәэмин итү.

Программа чаралары исемлеге һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты (алга таба – муниципаль бюджет) акчалары хисабына чараларны финанслау әлеге Программага 1 нче кушымтада китерелгән.

Программаны тормышка ашыру срогы – 2024-2026 еллар.

## 3 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Программаны 2024-2026 елларга финанслау күләме 29 730,00 мең сум тәшкил итә: 2024 ел – 9 910,00 мең сум, 2025 ел – 9 910,00 мең сум, 2026 ел – 9 910,00 мең сум.

Финанслау күләме фаразлау рәвешендә бирелә һәм, муниципаль бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## 4 бүлек. Программа белән идарә итү механизмы үз эченә алган Программаны тормышка ашыру механизмы

Чараларны тормышка ашыру барышына контрольне Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе гамәлгә ашыра.

Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе:

- Программа чаралары кысаларында гамәлләрне координацияләүне тәэмин итә;
- Программа бурычларын тормышка ашырганда алдынгы һәм фәнсыйдырышлы карарларны апробацияли һәм гамәлгә кертә;
- консультация, методик, хокукый ярдәм күрсәтә;
- квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 25 числосына кадәр, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә һәм Башкарма комитетның финанс идарәсенә Программаны финанслау турында мәгълүмат җибәрә;
- ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенә һәм Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге Программага 2 нче, 3 нче кушымталарда каралган формалар буенча Программаның нәтиҗәлелегенә анализ, тормышка ашыру барышы турында хисап тапшыра.

## 5 бүлек. Программа нәтиҗәлелеген бәяләү һәм көтелгән ахыргы нәтиҗәләрен тасвирлау

Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәсе булып Яр Чаллы шәһәре территориясендә җәмәгать иминлеген һәм хокук тәртибен тәэмин итү тора.

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге Программа белән расланган максатчан индикаторларның һәм күрсәткечләрнең фактик нәтиҗәләр дәрәҗәсе буларак бәяләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Программага 1 нче кушымта

| № т/б | Төп чараларның исеме | Башкаручы | Төп чараларны үтәү срогы | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты хисабына финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 (база) | 2024 | 2025 | 2026 | 2024 | 2025 | 2026 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Максат: җәмәгать иминлегенең, хокук тәртибенең һәм яшәү тирәлеге куркынычсызлыгының гомуми дәрәҗәсен арттыру | | | | | | | | | | | |
| Бурыч: Яр Чаллы шәһәре территориясендә иҗтимагый киңлекләрендә һәм күпфатирлы йортлар территориясендә тәртип һәм куркынычсызлыкның даими мониторингын тәэмин итү | | | | | | | | | | | |
| 1 | Җәмәгать киңлекләрендә видеокүзәтү камералары өчен элемтә каналларын тәкъдим итү хезмәтләре күрсәтү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | 2024-2026, ел саен | Хезмәт күрсәтелгән объектлар өлеше, гомуми саннан, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 4 500,00 | 4 500,00 | 4 500,00 |
| 2 | Җәмәгать киңлекләрендә видеокүзәтү камераларына техник һәм авария хезмәте күрсәтү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | 2024-2026, ел саен | Видеокүзәтү системаларына хезмәт күрсәтелгән һәм ремонт үткәрелгән объектлар өлеше, гомуми саннан, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 5 410,00 | 5 410,00 | 5 410,00 |
| 3 | Күпфатирлы йортлар территориясендә видеокүзәтү үсеше | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | 2024-2026 ел саен | Видеокүзәтү камералары урнаштырылган объектлар өлеше, гомуми саннан, % | 59 | 70 | 75 | 80 | Финанслау таләп ителми | | |

Программага 2 нче кушымта

## Программаның нәтиҗәлелегенә анализ

| № т/б | Бурычның, чараның исеме | Эшчәнлек нәтиҗәләре күрсәткечләре | | | | | Бюджет чыгымнарының күләме, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Күрсәткечнең исеме (шул исәптән индикаторны исәпләү формуласы яки күрсәткечнең чыганагы) | Үлчәү берәмлеге | План буенча күрсәткеч | Фактик зурлык | Тайпылу (-/+,%) | План буенча | Фактик | Тайпылу (-/+,%) |
| Бурыч | | | | | | | | | |
| 1. | Чара 1 | Нәтиҗәлелек индикаторы 1 | | | | | | | |
| | | Нәтиҗәлелек индикаторы 2 | | | | | | | |
| 2. | Чара 2 | Нәтиҗәлелек индикаторы 1 | | | | | | | |
| | | Нәтиҗәлелек индикаторы 2 | | | | | | | |
| 3. | Чара 3 | Нәтиҗәлелек индикаторы 1 | | | | | | | |
| | | Нәтиҗәлелек индикаторы 2 | | | | | | | |
| 4. | Чара ... | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |

Программага 3 нче кушымта

| Муниципаль программаның реквизитлары, тормышка ашыру чоры | |
|---|---|
| Муниципаль программаны раслау турында норматив хокукый актның исеме | |
| Форма төзү өчен җаваплы вазыйфаи зат (Ф.И.А.и., вазыйфасы, элемтә телефоны) | |

_________ елның _________ өчен
муниципаль программаны тормышка ашыру турында хисап

| № т/б | Ярдәмче программаларның (бүлекнең, чараның) исеме | Финанслау чыганагы (Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты) | Муниципаль программаны раслау турында норматив хокукый акттагы хисап елына план буенча финанслау күләме, мең сум | Хисап чорына муниципаль программа буенча бүлеп бирелгән (лимит), мең сум | Финанслау проценты | Фактик кулланылган чаралар, мең сум | Индикаторның исеме, үлчәү берәмлеге | Индикаторның зурлыгы | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | Узган ел | | Агымдагы ел | | | Киләсе елга план |
| | | | | | | | | план | факт | план | факт | Үтәлү проценты | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |